Котv чыгу – авыл тормышын, ритмын vзгәртә торган, дvрт кvзләп, санап котә торган зур вакыйга. Котәрсен дә, коздән туплаган ашлык - печән запасы кимеп барса...
Жәй ае керде, авылларда терлекләрне котvгә чыгарырга кvптән вакыт. Әмма кайбер авылларда әлеге мәсьәлә һаман хәл ителмәгән булса, Мордовиябезнен татарлар яшәгән районнарнын зур авылларында инде апрель урталарында ук котv чыккан. Аларда котvне авыл халкы чиратлап та котә, котvчегә акча тvләп тә коттерәләр. Кечкенә авылларнын да кvбесендә котv чыккан.   Билгеле, мал саны аз булгач, котvче яллап булмый. Шуна да кечкенә генә Зубово-Поляны районы Татар Лунданы авылында vз малларын vзләре котәләр.
Ләмберә районы Татар Тавла авылында дvрт дистәдән артыграк баш сыерлар асрыйлар. Яртысыннан кvбесен фермер Азат Рәстәм улы Алмакаев vстерә. Татар Тавла авылынын табигате матур, жәйләvләре иркен, тау асларында vлән житәрлек; шунда мал-туар рәхәтләнеп тукланып йори. Ә кайбер хужалар малларын печәнне чабып китергән vлән белән ашаталар.
Темников районы Тархан авылында гомер-гомергә зур-зур котvләр, башка авылларда тосле, чыга торган иде. Ә бvген сарыклар котvен генә чиратлап саклыйлар. Сыерлар аз асрыйлар, шунлыктан котvгә кумыйлар.
Кадошкино районы Латышовка авылындагы сарык котvе апрель азагында чыккан, әлегә биредә дә котvне чиратлап котәләр. Әмма кvрше Большие Поляны авылында сарыкларын я электрокотvче саклый, я vз тирәләрендә саклыйлар. Сыерлар асраучы да аз. Берничә фермер бар: алар да я vзләре саклый, я электрокотvче.
Менә шундый яналыклар бар авыл жирләрендә.

Н.ХӘЛИЛ